| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.10.2025 № 4

**Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару комиссиясен төзү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 31 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына туры китереп,Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару комиссиясен 1 нче кушымта нигезендә төзергә.

2.Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару комиссиясе турындагы нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3.Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Алексеевск муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Алексеевск шәһәр җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **И.К. Свистунов**

Алексеевск муниципаль
районы Алексеевск шәһәр
җирлеге Башкарма
комитетының 07.10.2025 ел,
№ 4 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару комиссиясе
составы

Комиссия рәисе:

Свистунов И.К.- Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе;

Комиссия рәисе урынбасары:

Павлова Э.Н.- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килештерү буенча);

Комиссия секретаре:

Увакина В.В.- Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары;

Комиссия әгъзалары:

Добрецов О.П.- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге депутаты, (килештерү буенча);

Доронов В.В.- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге депутаты, (килештерү буенча).

Алексеевск муниципаль
районы Алексеевск шәһәр
җирлеге Башкарма
комитетының 07.10.2025 ел,
№ 4 карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге » муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару комиссиясе турында
нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелеш алып баруны җайга салу системасын төзү, эзлекле камилләштерү һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару буенча комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә.

Комиссия Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә төзелә.

Комиссия даими эшли һәм үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

Комиссия үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр, шулай ук кызыксынган юридик һәм физик затлар белән берлектә алып бара.

## 2. КОМИССИЯ СОСТАВЫ

2.1. Комиссия составы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

2.2. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. КОМИССИИЯНЕҢ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

3.1. Комиссия компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

3.1.1. Җирдән файдалануны һәм төзелеш алып баруны җайга салу системасын эзлекле формалаштыру һәм камилләштерү, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен эшләү, ә киләчәктә аларны гамәлгә ашыру процессын оештыру;

3.1.2. Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен эшләүгә бәйле рәвештә гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;

3.1.3. Гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру:

- Алексеевск муниципаль районының«Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча;
- Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча;
- Алексеевск муниципаль районының«Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча;
- Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру проекты буенча;
- Алексеевск муниципаль районының« Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен ызанлау проекты буенча;

3.1.4. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча нәтиҗә чыгару, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тәкъдимнәр әзерләү.

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия кирәк булган саен җыела, ләкин аена бер тапкырдан да сирәгрәк түгел.

4.2. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, Комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия карары шунда катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч була.

4.4. Комиссия эшчәнлеген техник тәэмин итү Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетына йөкләнә.